СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 17 августы № 30/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 03.06.2020 № 45/4, 12.11.2020 № 3/6, 05.02.2021 № 6, 16.08.2021 № 11/3, 13.02.2023 № 25/1, 20.06.2023 № 29/6 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**9 статьяның 5 пунктына** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**9 статьяның 7 пунктына** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**19 статьяның 3 пунктының 1 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яисә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклады;».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 25 декабрендәге 35/3 номерлы карары белән (27.05.2021 № 9/4, 03.02.2022 № 16/4, 30.06.2022 № 20/4 редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәгә, **10.1 пунктында** «60 көннән» сүзләрен «30 көннән» сүзләре белән

алыштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2012 елның 13 декабрендәге 24/2 номерлы карары белән (13.11.2018 № 30/7, 25.03.2020 № 44/1 редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.4 пунктның икенче абзацында** «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

**2.5 пунктның икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яисә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклады;».

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2009 елның 5 июнендәге 42/9 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәр итү Тәртибенә, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибенә **4 өлешнең 4.2 пунктында** «белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан тулы булмаган белешмәләр бирү яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров